РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**посёлка городского типа**
**КАМСКОЕ УСТЬЕ**
***Камско-Устьинского***
**муниципального района**

ул. Советска, 11, пгт. Камское Устье, 422820
тел. (884377) 2-19-40, 2-15-76, факс: (884377) 2-14-76
ОКПО 78692631, ОГРН 1051651018484
ИНН/КПП 1622004531/162201001

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
***Кама Тамагы***
**муниципаль районы**
**Кама Тамагы**
**шәһәр тибындагы поселогы**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Совет урамы, 11,Кама Тамагы штп, 422820,
тел. (884377)2-19-40, 2-15-76, факс: (884377) 2-14-76
ОКПО 78692631 ОГРН 1051651018484
ИНН/КПП 1622004531/162201001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**2018 елның 13 сентябре** **№ 56**

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы шәһәр тибындагы Кама Тамагы поселогы Башкарма комитетының 2017 елның 19 апрелендәге “Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга шартнамә төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 5 санлы карарына үзгәрешләр кертү хакында
(2018 елның 1 августындагы 16 номерлы карар редакциясендә)

“Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү оештыру турында” 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы шәһәр тибындагы Кама Тамагы поселогы Башкарма комитетын **карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы шәһәр тибындагы Кама Тамагы поселогы Башкарма комитетының 2017 елның 19 апрелендәге 5 санлы карары белән расланган Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга шартнамә төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 5 бүлекнең 5.12 пунктындагы 1-3 абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“5.12. Шикаять карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шулай ук кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, муниципаль хезмәт курсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларга кертелгән опечаткаларны һәм хаталарны төзәтү, Россия Федерациясе норматив-хокукый актлары, Татарстан республикасы норматив-хокукый актлары, муниципаль норматив-хокукый актлар белән каралмаган түләүләрне кире кайтару формаларында;

2) шикаять канәгатьләндерелми.”.

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендлар аша халыкка белдерергә:

- шәһәр тибындагы Кама Тамагы поселогы, Совет ур., 11нче йорт, җирле үзидарә бинасы;

- шәһәр тибындагы Кама Тамагы поселогы, К.Маркс ур., 105нче йорт, китапханә, уку залы, шулай ук мәгълүмат-телекоммуникация «Интернет» челтәрендә хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы районы рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуын үз өстемә алам.

Җитәкче И.Ф. Яруллин